Укытучы, шагыйрь Равил Сәйфетдинов иҗатына

багышланган III Төбәкара Равил Сәйфетдинов укулары

# Тикшеренү проекты

# Равил Сәйфетдинов-табигать җырчысы

## (Равил Сәйфетдинов иҗатында туган як табигате бирелеше)

Башкардылар: ТР, Зеленодол шәһәре А.С.Пушкин исемендәге

9 нчы лицейның 7 нчы сыйныф укучылары -

Муллина Зәринә,Сөнгатуллина Айгөл, Юнысова

Динара

Җитәкче: Габидуллина Динә Гаязтин кызы, туган (татар) тел һәм

әдәбият укытучысы

Зеленодол, 2022

Эчтәлек

I.Кереш

II. Төп өлеш

1 нче бүлек. Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы

2 нче бүлек. Якташыбыз иҗатында туган як табигатенең чагылышы

III. Йомгаклау

IV. Кулланылган әдәбият

## Кереш

Шагыйрь турында күп beləсең килсә, аның тормыш юлын, иҗатын белергә кирәк. Ә ул үз чиратында дөньяның бөтен матурлыгын күрүче, күрсәтүче, әйтеп бирүче дә.

Без бик матур Яшел Үзән җирендә яшибез. Шәһәребез турында күп кенә шагыйрьләребез шигырьләр язалар, ләкин туган ягыбыз турында татар телендә алар бик аз.

Шуңа да **проектыбызның проблемасы**:

Якташыбыз Равил Сәйфетдиновның иҗаты белән танышу,үзебезнең тирә-як укучыларында кызыксындыру уяту, аларны шагыйрҗнең иҗат җимешләре белән таныштыру

Якташыбыз Равил Сәйфетдиновның иҗатын өйрәнүгә ихтыяҗ туды. Күренекле шагыйрь белән танышу, аның матур сүз остазы икәнлеген раслау эшебезнең а**ктуаллеген** билгели

**Тикшеренү предметы:**

Равил Сәйфетдиновның шигырьләре

Максатка ирешү өчен түбәндәге **бурычлар** куелды:

-шагыйрьнең шигырьләрен төрле чыганаклардан эзләү;

-туган як турында шигырьләрне табу;

-өстәл календаре эшләү

**Тикшеренү ысуллары:**

-мәгълүматны өйрәнү

-мәгълүматны эшкәртү

Проектның гипотезасы: якташыбызны күп укучылар белмиләр

**Тикшеренү этаплары:**

**1.Оештыру өлеше**

-теманы ачыклау

-эшнең планын билгеләү

**2. Практик өлеш**

-туган як турында шигырьләрне төрле  мәгълүматтан эзләү;

-мәктәп һәм шәһәр китапханәләренә бару;

-туган як  турында Равил абыйның  шигырьләрен уку;

-өстәл календаренә туган як турында шигырьләр сайлау

## 1 нче бүлек. Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы

Сәйфетдинов Равил Гарәфетдин улы 1938 нче елның 14 нче октябрендә Зеленодол районың Мулла Иле авылында туган.Урта мәктәпне бетергәч, 1956-1961 нче елларда Казан дәүләт университында укыган.1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән. Аннан туган авылына кайтып, рус теле һәм әдәбияты,немец теле, га-рәп теле, дин тарихы фәннәрен укыткан. 1968-1970 нче елларда-завуч, 1971- 2000 нче елларда мәктәп директоры булган.

Равил Сәйфетдинов- Россиянең мәгариф отличныгы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы, “Хезмәт ветераны” бүләге белән бүләкләнгән.

2005 нче елдан аллып Мулла Иле мәчете имам-хатыйбы вазифасын башкарган.2017 нче елда рухи-үхлакый үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килүшенү ныгыду зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән.

2018 нче елның 10 нчы февралендә вафат.

## 2 нче бүлек. Якташыбыз иҗатында туган як табигатенең чагылышы

Шагыйрьнең мәхәббәте, әлбәттә, ул туган авылы. Равил абыйның туган авылы -Мулла Иле. Шагыйрьнең “ Мулилем” шигырендә үз авылы турында болай яза:

Авылым, Мулилем,

Үстерәсең мул иген.

Мул игеннәр үскән җирем,

Гомерлегем бул илем

Равил абый туган авылын авылым, Мулилем, ди. Аның бу шигыре җыр булыр, ягъни авылның гимны булып киткән дип уйлыйбыз. Шигыйрьнең сүзләренә композитор Риф Гатауллин җыр язган.

Томаннарга төренеп пешә

Шомыртым, баланнарым,

Сиңа булсын, туган җирем,

Дәртләрем, дәрманнарым

Туган ягында томаннарга төренеп шомыртым, баланнарым пешә,  ди  Равил абый. Бер карасаң, ул тәмле җиләк-җимеш агачларын язмый, ә ачы,  төрле төстәге- кара, кызыл  җиләкләрне  сурәтли. Шагыйрьнең  бөтен көчен туган ягына бирәсе килә , “сиңа булсын дәртләрем”дәрманнарым”, ди.Ә чыннан да шагыйрь бөтен   гомерен туган иленә бирә, изге гамәлләр кыла: укытучы булып эшли , аннан  мулла булып тора.

Икенче шигырендә Равил Сәйфетдинов, әйтерсең, рәссам.”Авылым  җәе” шигырендә авылның  бөтен матурлыгын сурәтли.

Яратам мин сине, хезмәт белән

Дан казанган матур Мулилем.

Кырларында сине сөемә

Җавап булып үсә мул иген.

Әйтерсең рәсемендә безгә Равил абый безгә туган ягының бөтен гүзәлеген ясаган кебек. Ерак түгел Зөя ага , ул тулы, мул сулы, щ анда керәшәләр йөзә.

Күк гөмбәсе чагыла йөзендә.

Ярларыннан уктай атылып,

Керәләр уйный өстендә.

Елга тулы, мул сулы һәм аның өстендә керәшәләр( береговая ласточка) уйный

Икенче игътибарыбызны Равил абый  болынга җәлеп итә.

Буйларында сихри болыннар,

Яшел таллар-нечкә билләре.

Камышларга сыенып тын гына

Күккә карап яткан күлләре.

Авылның болынында яшел таллар, дөресрәге нечкә таллар үсә, күлләрендә камышлар үсә.

Елның тагын бер матур ел фасылы-ул көз. Равил Сәйфетдинов “Урак өсте” шигырендә болай дип яза:

Авыл тып-тын. Игенчеләр кырда,

Уңыш яулый күмелеп алтын нурга.

Офыкларда очынып бии рәшә,

Башакларга сыенып җил серләшә

Көзнең матурлыгын автор метафоралар белән бирә: “җил серләшә”, “рәшә бии”

Ак болытлар иркәлиләр җирне

Дөнья тулы тәмле башак исе.

Безнеңчә ,авылга тәмле ис таркала, авылда саф һава,

Үтте урак өсте.Көн сүрелде.

Кырлар чишенеп ятты йокларга.

Менә бү сүзләрне- “кырлар чишенеп ятты йокларга” , безнеңчә, Равил абый гына әйтә ала сыман.

Әйе, мондый матурлыкны гади күз күрми, бары шагыйрьләр генә безгә сөйләп, күрсәтеп бирә. Һәр ел фасылы шагыйрь өчен искиткич матур.

Язны Равил абый “иң матур кызы” дип атый. Язның бөтен матурлыгын берничә сүз белән әйтә дә бирә:

Килә яңа яшеллек алып

Табигатьнең иң матур кызы.

Килә шаулап, килә гөрелдәп

Ватанымның үзедәй язы

Равил Сәйфетдинов үз авылының туган ягын гына сурәтләми, ә Яшел Үзәннең күп авылларына “тукталып үтә”. ”Яшел Үзән” шигырендә районны биләп алган авылларының да матурлыгын сурәтли.

Чал Казаннан нурлар алып балкый

**Карагуҗасы, Күлбаш, Бишнәсе**.

Зур юлларга озатып кала сине

Ак бәхетләр теләп **Әйшәсе.**

Әлбәттә, Мулла Иленең күрше авыллары ул **– Норлат**, **Әрә**,**Танай, Күгеш** авыллары. Якташыбыз һәр авылның туган ягын ничек матур тасвирлый?! Менә Равил абый алар турында болай ди:

Дастан булып күтәрелә **Норлат,**

Еракларга сибелә нурлары.

Монда бит ул, монда алмаларның

Эрмекләнеп пешә торганы

Кил **Күгешнең** иркен кырларына,

Күр үскәнен ничек кәбестә.

Каюм Насыйриның туган авылын да калдырмый

Каюм бабай Насыйриның рухын

Саклый **Шырдан** , сауклый кадерләп.

Яши **Әрә**, яши Зөя, яши Идел-

Туган җирсез, туган телсезсез нишләр идем.

Барыбызга да якын булган шәһәр ул-Яшел Үзән.Ул –безнең “кечкенә мәркәзебез”, барлык авылларны бистәләрне берләштерүче шәһәр. Равил Сәйфетдинов та Яшел Үзәнебезне ярата, аңа багышлап шигырьләр яза.Менә ул “Яшел Үзән” шигырендә нәрсәләр яза:

Яшел Үзән диләр безнең якны

Гөлбакчадай матур булганга.

Чал Иделнең йомшак җиле белән

Бөдрә таллар шаулап торганга.

Якташыбыз Равил Сәйфетдинов “Зеленодольск “шигырендә үзенең мәхәббәтен шундый көчле икәнен мондый шигъри юллар белән яза:

Күпме шәһәрләрне күрмәдем мин,

Күпме хәйран калып йөрмәдем.

Тик алардан

Шашкын сагыну белән

Сиңа алып кайтты йөрәгем.

Шулай итеп, безгә Равил Сәйфетдинов үз шигырьләрендә туган якның матурлыгын күрергә, яратырга өнди.

**Йомгаклау**

Безнең алда куелган максат, бурычлар үтәлде:

1. Без якташыбыз Равил Сәйфетдиновның тормыш юлы, аның иҗат җимеше турында белемнәребезне ныгыттык. Якташыбызның иҗаты- серле бакча кебек икән, могҗизалы ил.Ул үзенә чакырып тора.

2. Равил абый шигырьләрен укып, туган ягыбызның тагын да матурлыгын күрергә өйрәндек

**Эшнең дәвам итү перспективалары**

1. Равил Сәйфетдинов иҗатын өйрәнүне дәвам итү.

2.Шагыйрьнең шигырьләренә иллюстрацияләр ясап, кечкенә китап ясау.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Мулла Иле моңнары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр җыентыгы. // Үзән, Казан, 2010

e·

Үзенең “Мин бит Мулла Иле баласы ” шигырендә үз авылын никадәр яратуын күрсәтәМин аың баласы ди. Безгә аңлашылмаган сүзләр бик күпШуңа карамастан авылдагы барлык вакыйгалар  л йөрәге аша чыгара

ны туган авылының төрле ел фасылы булуына карамастан, аның матурлыгы